КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 февраль г.Казань № 142

Карантин объектларына һәм чүп үләннәренә кертелмәгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә, федераль әһәмияттәге урманнардан һәм махсус сакланылучы табигать территорияләреннән тыш, аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару буенча чаралар күрелергә тиеш инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеген раслау турында

«Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $35^1$ статьясындагы 3 өлеше, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның $50^1$ статьясындагы 2 өлеше һәм Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Карантин объектларына һәм чүп үләннәренә кертелмәгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә, федераль әһәмияттәге урманнардан һәм махсус сакланылучы табигать территорияләреннән тыш, аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару буенча чаралар күрелергә тиеш инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеген расларга.
2. Бу карар 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 28 февраль, 142 нче
карары белән расланды

Карантин объектларына һәм чүп үләннәренә кертелмәгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә, федераль әһәмияттәге урманнардан һәм махсус саклanылучы табигать территорияләреннән тыш, аларны ачыклау, аларның таралуын булдырмау һәм аларны юкка чыгару буенча чаралар күрелергә тиеш инвазив (чит) үсемлекләрнең куркыныч төрләре исемлеге

1. Сосновский балтырганы (*Heracleum sosnowskyi* Manden.)
2. Беркетелгән кызлар винограды (*Parthenocissus inserta* (A.Kern) Fritsch)
3. Башаклы ырга (*Amelanchier spicata* (Lam) C.Koch)
4. Корычагач яфраклы өрәңге (*Acer negundo* L.)
5. Күп яфраклы люпин (*Lupinus polyphyllus* Lindl).
6. Вак чәчәкле кына (*Impatiens parviflora* DC)
7. Эт тигәнәге (*Bidens frondosa* L.)
8. Канада элодеясы (бака ефәге) (*Elodea canadensis* Michx).
9. Калаксыман эхиноцистис (*Echinocystis lobata (*Michx) Torr. A.Gray)
10. Пенсильвания корычагачы (*Fraxinus pensylvanica* Marshall).